СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«МИЧУРИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«МИЧУРИН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

2023 елның 1 марты

№1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 27 октябрендәге 7 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (15.10.2018 № 24, от 29.11.2018 № 34 үзгәрешләр белән)

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 27 октябрендәге 7 номерлы карарына (15.10.2018 № 24, от 29.11.2018 № 34 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карарның 2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 0,1 процентка карата:

- гараж һәм машина урыннары;

- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган салым салу объектларында, шул исәптән исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары;».

2.Әлеге карарны Мичурин авылы, Совет ур., 26 йорт-административ бина, Совет ур., 28 йорт-мәдәният йорты бинасы; Яңа Сережкино авылы, Үзәк ур., 9 йорт, Үзәк урам 15 йорт - мәктәп адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Ә.Иванова